# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
# ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

# КАРАР

«02» 02 2021 ел №344

Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Башкарма комитетының «Тукай муниципаль районы муниципаль мәгариф учреждениеләре хезмәткәрләренең хезмәтләренә түләү шартлары турында» 2018 елның 6 сентябрендәге 4049 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы өстәмә белем бирү оешмалары хезмәткәрләренең хезмәтләренә түләү шартлары турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Россия Федерациясе Хезмәт кодексы нигезендә, федераль законнарга туры килмәүне бетерү максатында

КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Башкарма комитетының «Тукай муниципаль районы муниципаль мәгариф учреждениеләре хезмәткәрләренең хезмәтләренә түләү шартлары турында» 2018 елның 6 сентябрендәге 4049 номерлы карары белән расланган (Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Башкарма комитетының 2020 елның 24 ноябрендәге 4539 номерлы карары редакциясендә) Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы өстәмә белем бирү оешмалары хезмәткәрләренең хезмәтләренә түләү шартлары турында нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

I бүлектә:

2 пунктның өченче һәм дүртенче пунктларын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«база оклады (база вазыйфаи окладьг), хезмәт хакының база ставкасы – һөнәри квалификация төркеме нигезендә һөнәри эшчәнлекне гамәлгә ашыручы муниципаль учреждение хезмәткәренең, компенсация, стимуллаштыру һәм социаль түләүләрне исәпкә алмыйча, минималь окладьг (вазыйфаи окладьг), хезмәт хакы ставкасы;

оклад (вазыйфаи оклад) – календарь ай өчен хезмәт (вазыйфаи) бурычларын үтәгән өчен хезмәткәрнең, компенсация, стимуллаштыру һәм социаль түләүләрне исәпкә алмыйча, хезмәт хакының билгеләп куелган күләме;».

2. Әлеге карарны Тукай муниципаль районының рәсми сайтында (https://tukay.tatarstan.ru/) һәм Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http//pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

3. Әлеге карар үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Башкарма комитет Җитәкчесе А.Р. Хәбибуллин